ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Татарстан Республикасында урманнардан файдалану турында» Татарстан Республикасы Законының 1 һәм 3 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында

. Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2015 елның 17 октябрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында урманнардан файдалану турында» 2008 елның 22 маендагы 22-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2008, № 5 (I өлеш); 2009, № 12 (I өлеш); 2011, № 6 (I өлеш); 2012, № 1, № 12 (I өлеш); 2013, № 12 (I өлеш); 2014, № 5, № 12 (II өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 статьяда:
а) 2 пунктта «башкарма хакимиятнең вәкаләтле федераль органы белән килештереп, » сүзләрен төшереп калдырырга;
б) 3 пунктта «башкарма хакимиятнең вәкаләтле федераль органы белән килештереп, » сүзләрен төшереп калдырырга;

2) 3 статьяның 3 өлешендә:
а) түбәндәге эчтәлекле $13^{4}$ пункт өстәргә:
«$13^{4}$) кече һәм урта эшкуарлык субъектлары белән Россия Федерациясе Урман кодексының $29^{1}$ статьясындагы 4 өлеше нигезендә төзелә торган урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсе буенча түләүне исәпләгәндә урманнарны саклау, яклау, торгызу чараларын үткәрүне тәэмин итү чыгымнарын ачыклау өчен кулланыла торган коэффициентны билгеләү;»;
б) түбәндәге эчтәлекле $13^{5}$ пункт өстәргә:
«$13^{5}$) урман фонды җирләре составындагы урман кишәрлекләренә карата урман кишәрлекләренең проект документациясен раслау;».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан,Кремль
2015 елның 3 ноябре
№ 90-ТРЗ